РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
АДАВ-ТУЛУМБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АДАВ-ТОЛЫМБАЙ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

04 март 2016 ел № 1-10

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Адав-Толымбай авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү турында карар
проекты хакында

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге Советының 2015 елның 1 июлендәге 1-66 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә, гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы, Адав-Толымбай авыл Советының 2007 елның 21 маендагы 5-17 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлегендә гавами тыңлаулар үткәрү турында»гы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

I. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1. 1 статьяда:

үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлеге муниципаль берәмлегенә авыл җирлеге статусы бирелгән.

2. Муниципаль берәмлекнең рәсми исеме Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав - Толымбай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге (алга таба текст буенча - торак пункт).

3. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы составына керә.»;

2. 5 статьяда:

1 пунктның 7 пунктчасын үзгәртеп һәм түбәндәге редакциядә язырга:

«7) җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;»;

16 нчы пунктны өстәргә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16) торак пунктта яшәүчеләрнең күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буйларына иркле керүен тәэмин итү.»;

3. 19 статьяда:

4 нче пунктның 3 нче пунктын үзгәртеп һәм түбәндәге редакциядә язырга:

«4) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә районны үзгәртеп кору өчен муниципаль берәмлек халкының тавыш бирү юлы белән яки гражданнар җыеннарында белдерелгән ризалыгын алу таләп ителә.»;

4. 28 статьяда:

5 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«5. Җирлек советының тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен үтәү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы гербы сурәтләнгән мөһер, үз атамасы белән бланклары бар.»;

5. 30 статьяда:

3 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«3. Депутат, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазифалы зат, муниципаль вазифаны биләүче башка зат "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә тиеш. "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге 230 номерлы "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында" федераль закон, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы "Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата средстволарны һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында"гы федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәү, бурычларны үтәмәү очрагында депутат, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләүче башка затның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.»;

6 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

6. Депутат, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазифалы зат, муниципаль вазифаны биләүче башка зат "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә тиеш. "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге 230 номерлы "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында" федераль закон, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы "Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачуны һәм аларга ия булуны, акчалата средстволарны һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында"гы федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәү, бурычларны үтәмәү очрагында депутат, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләүче башка затның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.»;

7 пунктны өстәргә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«7. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутат, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазифалы кеше түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) эшкуарлык эшчәнлеге белән шәхсән яисә ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә, шулай ук хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә (торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларыннан, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларыннан, күчемсез милек милекчеләре ширкәтеннән һәм билгеләнгән тәртиптә теркәлгән профсоюздан тыш) катнашырга, әгәр федераль

законнарда һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә башкасы каралмаган булса яисә муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә аңа әлеге оешма белән идарә итүдә катнашырга кушылмаган булса;

2) укыту, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнү. Шул ук вакытта укыту, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый;

3) идарә органнары, попечительлек яки күзәтү советлары, чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган оешмаларның һәм Россия Федерациясе территориясендә эшләүче аларның структур бүлекчәләренең башка органнары составына керергә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса.»;

8 пунктны өстәргә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«8. Даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең депутат, сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты гражданлык, административ яисә җинаять эше буенча йә административ хокук бозу турындагы эш буенча яклаучы яисә вәкил (законлы вәкиллек очракларыннан тыш) сыйфатында катнаша алмый.»;

6. 40 статьяда:

1.1 п. өстәргә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләүче башка зат вәкаләтләре «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәгән очракта вакытыннан алда туктатыла.»;

7. 41 статьяда:

2 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«2. Җирлек башлыгы җирлек Советы тарафыннан сайлана һәм аның рәисе булып тора.»;

8. 43 статьяда:

6 пунктны өстәргә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«6. Җирлек башлыгы гражданлык, административ яисә җинаять эше буенча яки административ хокук бозу турындагы эш буенча яклаучы яки вәкил (законлы вәкиллек очракларыннан тыш) сыйфатында катнаша алмый.»;

9. 46 статьяда:

4 пунктны өстәргә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«4. Җирлек Советы тарафыннан сайланган җирлек башлыгы, аның вәкаләтләре җирлек Советының аны отставкага чыгару турындагы карары нигезендә вакытыннан алда туктатылган очракта, күрсәтелгән карарга суд тәртибендә шикаять бирә, җирлек Советы суд карары закон көченә кергәнче җирлек башлыгын сайлау турында карар кабул итәргә хокуксыз.»;

10. 47 статьяда:

4пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«4. Җирлекнең башкарма комитеты Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы гербы сурәтләнгән һәм үз исеме белән мөһер, бланклар, шулай ук аңа тапшырылган гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу һәм нотариаль гамәлләр кылуга вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе гербы сурәтләнгән түгәрәк мөһер, бланклар тота.»;

11. 49 статьяда:

4 пунктның 2 абзацын) үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итә, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыра;»;

12. 58 статьяда:

түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«1. Азат ителмәгән нигездә эшләүче җирлек Советы депутаты җирлек Советы һәм аның органнары утырышларында катнашу вакытына, җирлек Советы йөкләмәләрен үтәү өчен гамәлдәге законнарда каралган акчалата компенсация һәм башка түләүләр түләнергә мөмкин.

2. Әлеге Уставта каралган очракларда җирлек башлыгы вазыйфаларын башкарганда үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирлек башлыгының урынбасарына җирлек башлыгының айлык акчалата түләвенең 90% күләмендә бүләкләү түләнә.

3. Әлеге органнар эшендә катнашу вакытына җирлекнең ревизия комиссиясе һәм җирлек сайлау комиссиясе әгъзаларына җирлек Советы карарлары нигезендә акчалата компенсация түләнергә мөмкин.»;

13. 67 статьяда:

1 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«1. Җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү йөзеннән түбәндәге муниципаль хокукый актлар чыгаралар:

1) җирлек Советы - җирлек Советы карарлары;

2) җирлек башлыгы - җирлек башлыгының карарлары һәм күрсәтмәләре;

3) җирлекнең башкарма комитеты - карар һәм күрсәтмәләр.»;

14. 79 статьяда:

2 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«2. Җирлек бюджеты проекты, җирлек Советының җирлек бюджетын раслау турындагы карары, аның үтәлеше турындагы еллык отчеты, җирлек бюджетын үтәү барышы һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны турында квартал саен бирелә торган белешмәләр, аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнарны күрсәтеп, рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.».

II. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проектын расланргга.

III. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына» интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

IV. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты буенча килгән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә, түбәндәге составта:

эшче төркем җитәкчесе:

Еремеев Илдар Фәрид улы-Буа муниципаль районы башлыгының беренче урынбасары,

эшче төркем әгъзалары:

Даутов Сәлим Фәһим улы-Буа район башкарма комитеты җитәкчесе,

Сибгатуллин Ансар Мансур улы-Буа район Советының муниципаль милек белән идарә итү һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясе рәисе,

Вәлиева Резеда Нәгыйм кызы-ТР Буа муниципаль районы Советы аппаратының җирлекләр белән эшләү бүлеге башлыгы,

Мифтахов Фәнис Фәриз улы – ТР Буа муниципаль районы Советы Аппаратының юридик бүлеге башлыгы.

V. Билгеләргә:

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проектына тәкъдимнәр Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге советына эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр рәсми халыкка игълан ителгән (урнаштыру) көннән алып 30 көн эчендә язмача рәвештә 422404, ТР, Буа районы, Адав-Толымбай авылы, Урта ур., 99 адресы буенча кертелә;

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларда катнашуга заявкалар түбәндәге адрес буенча бирелә: 422404, Татарстан Республикасы, Буа районы, Адав-Толымбай авылы, Урта урам, 99 йорт, эш көннәрендә 8.00

сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, гавами тыңлаулар уздыру датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча.

VI. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлегенең 2007 елның 21 маендагы 5-17 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлегендә гавами тыңлаулар үткәрү турында нигезләмәдә» каралган тәртиптә 2016 елның 07 апреленә, 11.00 сәгатьтә Адав-Толымбай авыл мәдәният йорты бинасында 424204, Татарстан Республикасы, Буа районы, Адав-Толымбай авылы, Совет урамы, 19 йорт адресы буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

VII. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проектына тәкъдимнәрне өйрәнергә һәм гомумиләштерергә

VIII. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районы
Адав-Толымбай авыл җирлеге
башлыгы, ТР Буа муниципаль
районы Адав-Толымбай авыл
җирлеге Советы Рәисе А.Ф. Хөсниева